**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ ДӨРЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

26.09.2016 ел № 15/7

**Физик затлар мөлкәтенә салым турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында»2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Иске Дөреш авыл җирлеге территориясендә салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар милкенә салымны мәҗбүри түләүгә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым салу ставкалары күләмен билгеләргә.

3. Ике фатирдан торган күп фатирлы торак йорттагы фатирга милек хокукы булган физик затларга әлеге фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метры кадастр бәясенең процент өлеше буларак билгеләнә торган салым суммасын киметү рәвешендә ташламалар билгеләргә.

Бу очракта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы аны исәпкә алмыйча исәпләнгән салым суммасыннан артмаска тиеш.

4. Үз көчен югалткан дип танырга:

«Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2014 елның 12 ноябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 23 номерлы карары;

«Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 19 маендагы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» муниципаль берәмле Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 14 номерлы карары;

«Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015

елның 15 октябренәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» муниципаль берәмле Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2/7 номерлы карары.

5. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин җирлекнең мәгълүмат стендларында һәм ТР хокукый рәсми мәгълүмат порталында рәсми урнаштырылган көннән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,

Совет рәисе И.Х. Бакиров